# КАРАР

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы**
**Түбән Биш авыл җирлегенең Шыкмай торак пунктында**
**2025 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында**
**гражданнар җыены**

**2024 елның 25 ноябре** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Түбән Биш авыл җирлеге Шыкмай торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Түбән Биш авыл җирлеге Шыкмай торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 600 (алты йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә, шул исәптән көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, I төркем инвалидларыннан, ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан тыш.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә (үзәк урамындагы суүткәргеч торбаны өлешчә алыштыру);
- урамнарны тышкы яктырту челтәрләрен, трансформаторларны һәм алар астындагы башка подстанцияләрне һәм мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (урамнарны яктыртуны ремонтлау).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Түбән Биш авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Зәй муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы» нда урнаштырырга (PRAVO.TATARSTAN.RU) кабул ителгән көннән алып 7 көн дәвамында (Түбән Биш авыл җирлеге Уставының 69 п. 5 ст.).

**Гражданнар җыенында рәислек итүче,**
**Түбән Биш авыл җирлеге башлыгы**
**Зәй муниципаль районы** **А.Р.Гильфанова**